**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 5 февралендәге 260 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2016 елның 11 апрелендәге 1471 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан күпфункцияле үзәкләрдә күрсәтелә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеген раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Казан шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан күпфункцияле үзәкләрдә күрсәтелә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлегенә төгәллек кертү һәм аны киңәйтү максатыннан **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2016 елның 11 апрелендәге 1471 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан күпфункцияле үзәкләрдә күрсәтелә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеген раслау турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2016 елның 21 декабрендәге 5208 номерлы, 2018 елның 16 маендагы 2358 номерлы, 2018 елның 22 ноябрендәге 5936 номерлы, 2019 елның 12 февралендәге 502 номерлы, 2019 елның 16 апрелендәге 1444 номерлы, 2020 елның 29 гыйнварындагы 224 номерлы, 2020 елның 8 апрелендәге 1046 номерлы, 2021 елның 17 февралендәге 369 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 һәм 2 номерлы кушымталарны гамәлдән чыккан дип танырга;

1.2. әлеге карарның 1 һәм 2 номерлы кушымталарын, шул ук тәртиптә куеп, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2016 елның 11 апрелендәге 1471 номерлы карарының 1 һәм 2 номерлы кушымталары дип санарга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 5 февралендәге
260 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан күпфункцияле үзәкләрдә күрсәтелә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеге**

| № т/б | Дәүләт яки муниципаль хезмәт атамасы |
|---|---|
| **Җирле үзидарә органнарына бирелгән вәкаләтләр буенча күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре** | |
| **Балигъ булмаган затларны опекага алу һәм попечительлек итү мәсьәләләре** | |
| 1 | Балигъ булмаган затлар катнашында милекне залогка (ипотекага) бирүгә рөхсәт бирү |
| 2 | Балигъ булмаган затның милкенә караган мәсьәләләрне хәл итү өчен өченче затка ышанычнамә тутыруга рөхсәт бирү |
| 3 | Ундүрт яше тулмаган баланың исемен һәм (яки) фамилиясен үзгәртүгә рөхсәт бирү |
| 4 | Балигъ булмаган затны эмансипацияләү турында карар кабул итү (балигъ булмаган затны тулысынча эшкә сәләтле дип игълан итү) |
| 5 | Балигъ булмаган затның күчемсез милкен аңардан мәҗбүри алу буенча алыш-бирешләргә беренчел рөхсәт бирү |
| **Гражданлык хәле актларын теркәү мәсьәләләре** | |
| 6 | Гражданлык хәле актларын дәүләт теркәве турында таныклык һәм гражданлык хәле актын дәүләт теркәве фактын раслаучы башка документларны (белешмәләрне) кабаттан бирү (дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза кабул итү өлешендә) |
| **Муниципаль хезмәтләр** | |
| 1 | Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую һәм яңадан теркәү (исәпкә кую өлешендә) |
| 2 | Гражданнарны торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу |
| 3 | Социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны бирү |
| 4 | Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннары алуга мохтаҗ гражданнарны исәпкә кую |
| 5 | Күпфатирлы йортта торак урынны үзгәртеп коруны һәм (яки) үзгәртеп |

| №<br>т/б | Дәүләт яки муниципаль хезмәт атамасы |
|---|---|
| | планлаштыруны килештерү |
| 6 | Торак урынны торак булмаган урын итеп һәм торак булмаган урынны торак урын итеп үзгәртүгә рөхсәт бирү |
| 7 | Бакча йортын торак йорт итеп һәм торак йортны бакча йорты итеп тану |
| 8 | Муниципаль торак фондында гражданнарга хезмәт торак урынын наем шартнамәсе буенча торак урыннары бирү |
| 9 | 16 яшьтән өлкәнрәк балигъ булмаган гражданинның өйләнешү яшен киметүгә рөхсәт бирү |
| 10 | Белешмә (өземтә) бирү |
| 11 | Элек хосусыйлаштырылган торак урыннарын муниципаль милеккә кабул итү |
| 12 | Торак фондының гражданнар биләгән торак урыннарын алар милкенә тапшыру (торак фондын хосусыйлаштыру) |
| 13 | Яшь гаиләне торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ һәм (яисә) «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» төбәк проектында катнашучы дип тану |
| 14 | Торак урыннарны Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең махсуслаштырылган торак фонды составына кертү һәм аның составыннан чыгару |
| 15 | Бүлмәне торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә тиешле яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану |
| 16 | Муниципаль торак фондының социаль наем шартнамәсе нигезендә бирелгән торак урыннарын алмаштыру белән бәйле документларны рәсмиләштерү |
| 17 | Капиталь төзелеш объекты төзелешенә рөхсәт бирү (шул исәптән, мондый рөхсәтнең гамәлдә булу срогын озайтуга бәйле рәвештә капиталь төзелеш объекты төзелешенә рөхсәт бирү) |
| 18 | Планлаштырылган төзелеш турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән шәхси торак төзелеше объекты яисә бакча йорты параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм шәхси торак төзелеше объектын яисә бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыру мөмкинлеге турында хәбәрнамә җибәрү |
| 19 | Төзелгән яки реконструкцияләнгән шәхси торак төзелеше объектларының яки бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килүе турында хәбәрнамә җибәрү |
| 20 | Объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирү |
| 21 | Ана (гаилә) капиталы акчаларын җәлеп итеп, шәхси торак төзелеше объектын төзү (реконструкцияләү) буенча төп эшләр башкаруны тикшерү актын бирү |
| 22 | Җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектын саклап калу эшләрен башкаруга йөкләмә бирү |
| 23 | Ясалма җир кишәрлеген булдыру эшләрен башкаруга рөхсәт бирү |
| 24 | Ясалма рәвештә булдырылган җир кишәрлеген файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү |
| 25 | Реклама корылмаларын урнаштыруга һәм файдалануга рөхсәт бирү, рөхсәтне |

| №<br>т/б | Дәүләт яки муниципаль хезмәт атамасы |
|---|---|
| | гамәлдән чыгару |
| 26 | Тышкы төзекләндерү элементларына зыян китерү белән бәйле җир эшләрен башкару өчен рөхсәтләрне (ордерларны) теркәү, рәсмиләштерү, бирү һәм озайту |
| 27 | Агачларны, куакларны кисүгә, аларның ябалдашларын формалаштырып кисүгә, утыртуга һәм күчереп утыртуга, газонны бетерүгә рөхсәт бирү |
| 28 | Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан файдаланучыларга автомобиль юлларының торышы турында мәгълүмат бирү |
| 29 | Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең автомобиль юлларында хәрәкәтне вакытлыча чикләүгә яисә туктатуга рөхсәтләр бирү |
| 30 | Яңгыр һәм кар суларын читкә чыгаруга, төзелә торган капиталь төзелеш (реконструкция) объектлары территориясен төзекләндерү эшләрен башкаруга һәм юл сервисы объектларын Казан шәһәренең җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларына тоташтыруга техник шартлар һәм техник шартларны үтәү хакында белешмә бирү |
| 31 | Муниципаль милектәге су объектларын судан файдалану шартнамәсе яисә су объектын файдалануга тапшыру турындагы карар нигезендә файдалануга бирү |
| 32 | Су объектлары төпләрен һәм ярларын үзгәртүгә бәйле рәвештә су төбен тирәнәйткәндә һәм башка эшләр башкарганда су төбеннән алынган туфракны файдалану турында карар кабул итү |
| 33 | Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү |
| 34 | Шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасында булган мәгълүматларны бирү |
| 35 | Адресация объектына адрес бирү, мондый адресны үзгәртү һәм гамәлдән чыгару |
| 36 | Объектның (проектлана һәм реконструкцияләнә торган капиталь төзелеш объектларының, керү урыннарының һәм территорияне төзекләндерү объектларының) архитектура-шәһәр төзелеше ягыннан күренешен килештерү |
| 37 | Төзелеш белән бәйле булмаган эшләр: объектларның тышкы өлешенә капиталь ремонт ясау, фасадларның төсен сайлау һәм декоратив бизәү, стационар булмаган сәүдә объектлары һәм сезонлы объектлар урнаштыру, территорияне төзекләндерү элементлары, тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру концепциясе, объектларның архитектура-сәнгать ягыннан яктыртылышы өлешендә объектның архитектура-шәһәр төзелеше күренешен килештерү (объект паспорты) |
| 38 | Җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектын саклап калу эшләрен башкаруга йөкләмә бирү |
| 39 | Җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектын саклау эшләрен башкаруга проект документларын килештерү |
| 40 | Капиталь төзелеш объектын сүтүне планлаштыру турында хәбәрнамә җибәрү һәм капиталь төзелеш объектын сүтүне тәмамлау турында хәбәрнамә җибәрү |
| 41 | Мәгълүмат тактасын урнаштыру, элмә такта урнаштыруның дизайн-проектын килештерү |

| №<br>т/б | Дәүләт яки муниципаль хезмәт атамасы |
|---|---|
| 42 | Проект документларының җир асты инженерлык коммуникацияләре һәм корылмалары картасына (планына) туры килүе турында бәяләмә бирү |
| 43 | Электромобильләр өчен парковка рөхсәтләре реестрына электромобиль өчен парковка рөхсәте турында язма кертү, электромобиль өчен парковка рөхсәте турындагы язманы үзгәртү һәм электромобиль өчен парковка рөхсәтенең гамәлдә булу вакытын озайту турында мәгълүматлар кертү |
| 44 | Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташуның муниципаль маршрутын тормышка ашыру турындагы таныклыкны һәм даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташуның муниципаль маршрут карталарын рәсмиләштерү, яңадан рәсмиләштерү, гамәлдә булуын туктату |
| 45 | Торак пунктлар өстендә авиация эшләрен, парашют белән сикерүләрне, һава судноларының күрсәтмә очышларын, пилотсыз очу аппаратлары очышларын башкаруга, бәйләп куела торган аэростатларны күтәрүгә, шулай ук торак пунктлар чикләрендә урнашкан һәм алар турында белешмәләр аэронавигация мәгълүматы документларында басылып чыкмаган мәйданчыкларга төшүгә (очып китүгә) рөхсәтләр бирү |
| 46 | Юл билгеләрендә аерым проект нигезендә башкарылган мәгълүмат билгеләрен урнаштыруны килештерү |
| 47 | Россия Федерациясе законнары нигезендә гражданнарны пенсия белән тәэмин итүне, шулай ук аларның ташламалар һәм компенсацияләр алуларын күз алдында тоткан гражданнарны социаль яклауга бәйле архив белешмәләрен, архив өземтәләрен һәм архив күчермәләрен алу буенча мөрәҗәгатьләрен үтәүне оештыру |
| 48 | Территориянең кадастр планында җир кишәрлеге яки җир кишәрлекләре урнашу схемасын раслау |
| 49 | Территориянең кадастр планында җир кишәрлеге урнашу схемасын раслау турында яки, расланган территорияне ызанлау проекты нигезендә, дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм хосусый милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзүгә ризалык бирү турында карар кабул итү |
| 50 | Җирдән файдаланучы, җир хуҗасы җир кишәрлегенә булган хокукыннан баш тарткан очракта, җир кишәрлегеннән даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану һәм аны гомерлек мирас рәвешендә биләү хокукын туктату |
| 51 | Җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитут, ачык сервитут билгеләмичә, муниципаль милектә булган җирләрдән яисә җир кишәрлегеннән файдалануга рөхсәт бирү |
| 52 | Муниципаль милектәге җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү |
| 53 | Муниципаль милектәге җир кишәрлеген милеккә түләүсез бирү |
| 54 | Муниципаль милектәге җир кишәрлеген, сатулар үткәрмичә, милеккә, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, бушлай файдалануга бирү |
| 55 | Муниципаль милектәге җир кишәрлегенә сервитут (ачык сервитут) билгеләү |

| № т/б | **Дәүләт яки муниципаль хезмәт атамасы** |
|---|---|
| 56 | Гражданнарны җир кишәрлекләрен бушлай милеккә алу хокукына ия затлар буларак исәпкә кую |
| 57 | Казан шәһәре муниципаль милкеннән түләүсез файдалану шартнамәсен мондый шартнамәне төзү хокукына сатулар нәтиҗәсе нигезендә төзү |
| 58 | Муниципаль милекне сатулар үткәрмичә арендага, түләүсез файдалануга бирү |
| 59 | Муниципаль милекне арендалауның гамәлдәге килешүен өзү |
| 60 | Муниципаль милекне арендалау, түләүсез файдалану шартнамәсенә үзгәрешләр кертү турында өстәмә килешү төзү |
| 61 | Муниципаль милек реестрыннан исәпкә алынган объектлар турында мәгълүмат бирү |
| 62 | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары арендалана торган милекне милеккә сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда, алар тарафыннан арендалана торган, муниципаль милеккә караган күчемле һәм күчемсез милекне бирү |
| 63 | Арендага бирү өчен билгеләнгән һәм муниципаль милектәге күчемсез милек объектлары турында мәгълүмат бирү |
| 64 | Ваклап сату базарын оештыру хокукына рөхсәт бирү |
| 65 | Муниципаль милектәге җирләрдә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамә төзү |
| 66 | Муниципаль контроль чараларын үткәрүгә җәлеп ителә торган экспертларны аттестацияләү |
| 67 | Мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләренә балаларны исәпкә кую һәм җибәрү |
| 68 | Каникул вакытында балаларның ялын оештыру |
| 69 | Спорт судьяларының квалификация категорияләрен бирү |
| 70 | Спорт разрядларын бирү |

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 5 февралендәге
260 номерлы карарына
2 номерлы кушымта

**Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә комплекслы запрос ярдәмендә Казан шәһәре Башкарма комитеты органнары тарафыннан күрсәтелми торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеге**

| № т/б | Дәүләт яки муниципаль хезмәт атамасы |
|---|---|
| **Җирле үзидарә органнарына бирелгән вәкаләтләр буенча дәүләт хезмәтләре** | |
| **Балигъ булмаган затларны опекага алу һәм попечительлек итү мәсьәләләре** | |
| 1 | Балигъ булмаган затлар катнашында милекне залогка (ипотекага) бирүгә рөхсәт бирү |
| 2 | Балигъ булмаган затның милкенә караган мәсьәләләрне хәл итү өчен өченче затка ышанычнамә тутыруга рөхсәт бирү |
| 3 | Ундүрт яше тулмаган баланың исемен һәм (яки) фамилиясен үзгәртүгә рөхсәт бирү |
| 4 | Балигъ булмаган затны эмансипацияләү (балигъ булмаган затны тулысынча эшкә сәләтле дип игълан итү) турында карар кабул итү |
| 5 | Балигъ булмаган затның күчемсез милкен аңардан алу буенча алыш-бирешләргә беренчел рөхсәт бирү |
| **Гражданлык хәле актларын теркәү мәсьәләләре** | |
| 6 | Гражданлык хәле актларын дәүләт теркәве турында таныклык һәм гражданлык хәле актын дәүләт теркәве фактын раслаучы башка документларны (белешмәләрне) кабаттан бирү (дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза кабул итү өлешендә) |
| **Муниципаль хезмәтләр** | |
| 1 | Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую һәм яңадан теркәү (исәпкә кую өлешендә) |
| 2 | Гражданнарны торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу |
| 3 | «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасы буенча исәпкә кую, ел саен яңадан теркәү һәм торак алу (төзү) өчен социаль түләү алу хокукы турында таныклык бирү |
| 4 | Тышкы төзекләндерү элементларына зыян китерү белән бәйле җир эшләрен башкару өчен рөхсәтләрне (ордерларны) теркәү, рәсмиләштерү, бирү һәм озайту |
| 5 | Мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф |

| № т/б | Дәүләт яки муниципаль хезмәт атамасы |
|---|---|
| | учреждениеләренә балаларны исәпкә кую һәм җибәрү |
| 6 | 16 яшьтән өлкәнрәк балигъ булмаган гражданинның өйләнешү яшен киметүгә беренчел рөхсәт бирү |